РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

21.08.2024 №14

Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының 06.05.2019 елгы №22 карары белән расланган Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 06.05.2019 елгы №22 карары белән расланган Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1. Нигезләмәнең 3 пункт таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңнән артык кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 23 700 | 25 000 |
| Бухгалтер | - | 22 500 |

».

2. . Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы Д.М.Гайнетдинов

AnyScanner